ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кукмара муниципаль районы
Югары Чура авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2020 елның 28 гыйнваре — 3 номерлы

Югары Чура авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 35 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Югары Чура авыл җирлеге карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге Югары Чура авыл җирлеге Советының 35 номерлы карарына ((Югары Чура авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 32 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 23 номерлы, 2015 елның 26 ноябрендәге 15 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 11 номерлы, 2018 елның 7 ноябрендәге 29 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 33 номерлы, 2018 елның 21 декабрендәге 37 номерлы,2019 елның 28 ноябрендәге 23 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кадастр хакының 0,1% ы – 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: www.pravo.tatarstan.ru, шулай ук Югары Чура авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында да.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары — А.Н. Афанасьев